СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2021 ел** **№ 34**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 февралендәге 21 номерлы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендә булган җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” карарына үзгәрешләр кертү турында (30.03.2021 №22 үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне рациональ файдалану, саклау һәм яңадан торгызу максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2021 елның 17 февралендәге 21 номерлы карары белән (30.03.2021 №22 үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендә булган җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Авыл җирлеге башкарма комитеты гариза бирүче хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач өчен түләүне (бәя) исәпләү нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисүгә гариза бирү көнен дә кертеп, 13 көн эчендә рөхсәт итү турындагы күрсәтмәсе проектын әзерли.»;

2) 3.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Агач кискән өчен түләүне башкармыйча, агач һәм куакларны кисү түбәндәге очракларда авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан рөхсәт ителә ала:

3.11.1. яшел үсентеләрне тәрбияви кисүләр, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү;

3.11.2. авария һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау вакытында;

3.11.3. әгәр дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм җәмәгать биналарында яктылык режимын боза торган агач һәм куакларны кисү;

3.11.4. җимерелү куркынычы тудыра торган авария хәлендәге (корыган) агачлар һәм куакларны кисү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында “Җирлекләр” бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов